

Ләмберә районында Мәдәният сарае тозелv турында хәбәрдарбыз. Яна бинада фольклор Үзәге дә эшләячәк. Анда борынгы татар йорты макеты белән дә танышып булыр.	Бу районда ата – бабаларыбыз калдырган раритетларны саклаучы кешеләр кvп булуы беркемгә дә сер тvгел. Шуларнын берсе – Татар Тавласы авылыннан Альмира Сәяф кызы Абузярова (фотода). Ул егерме елдан артык мәдәният олкәсендә эшләгән һәм бvгенге конгә кадәр районда vткәрелә торган кvп кенә чараларда актив катнашкан – татар жанлы ул. Альмира Сәяф кызы, «Татар ое» экспозициясен тулыландырып, бvләк ясаган: сандык, ике мендәр һәм ике козге бvләк иткән.